ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«06» 05 2026 Яр Чаллы шәһәре №44

Территорияне планлаштыру проекты, «Яр Чаллы - Сарман автомобиль юлын реконструкцияләү, км 22+480-км 26+030» линия объекты территориясен ызанлау проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2026 елның 24 апрелендәге 01-09-9935 номерлы хаты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Территорияне планлаштыру проекты, «Яр Чаллы - Сарман автомобиль юлын реконструкцияләү, км 22+480-км 26+030» линия объекты территориясен ызанлау проекты буенча халык тыңлауларын билгеләргә.
2. Халык тыңлауларын оештыручы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына җирле үзидарә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар нигезендә халык тыңлауларын оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.
3. Халык тыңлауларын үткәрү 2026 елның 15 июненнән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.
4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Д.Ф. Вәлиуллинга йөкләргә.

Район Башлыгы К.Р. Нәҗмиев